# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак авылы торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**17 ноябрь 2023 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 17 ноябрендә 8.30 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2024 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлар; тыл хезмәтчәннәре; көндезге бүлек студентлары; хәрби хезмәт һәм контракт буенча үтүче гражданнар; мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү; (ЗИЛ-131 автомобиле: ягулык-майлау материаллары, запас часть, гидрантлар урнаштыру);

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту ; (вак таш сатып алу, юлларны грейдирлау,МТЗ-82: ягулык-майлау материаллары, түләү, запас часть);

4) халыкның күпләп ял итү урыннарын( парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (территорияләрне кисү, түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

5)ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зират өчен инвентарь)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 26 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 14 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 14 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл жирлегенең Анак авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2024 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, урам яктырту җайланмасы (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам яктыртуга хезмәт күрсәтү);

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү; (ЗИЛ-131 автомобиле: ягулык-майлау материаллары, запас часть, гидрантлар урнаштыру);

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту ; (вак таш сатып алу, юлларны грейдирлау,МТЗ-82: ягулык-майлау материаллары, түләү, запас часть);

4) халыкның күпләп ял итү урыннарын( парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (территорияләрне кисү, түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

5)ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зират өчен инвентарь

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Кәшер авыл җирлегенең Анак мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районыньл рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәисе Р.Н. Дәүләтҗанов